## I. Укыту предметын үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләре

Сыйныф: 2 “А”
Атнага: 2 сәг.
Барлыгы: 70 сәг.

Программа түбәндәге документлар нигезендә төзелде:

1. Программа: Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы. Урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә рус телле балаларга татар телен коммуникатив технология нигезендә укыту программасы (1 — 11 нче сыйныфлар). Төзүче – авторлары: Р.З. Хәйдәрова, Р. Л. Малафеева, Әхмәтҗанова, 2017 ел.

2. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем учреждениясе “Аерым предметларны тирәнтен өйрәнүче Алексеевск 2 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе”нең төп гомуми белем бирү баскычында башлангыч гомуми белем бирү программасы.
3. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем учреждениясе “Аерым предметларны тирәнтен өйрәнүче Алексеевск 2 нче урта гомуми белем мәктәбе”нең 2018-2019 уку елына укыту планы (№ ____педсовет протоколы, __ ________ 2018 ел).

Дәреслек: ”Күңелле татар теле” ”. Дүртьеллык башлангыч мәктәпенең 2 нче сыйныф рус балалары өчен татар теле һәм уку дәреслеге. Р.З. Хәйдәрова, Н.Г. Галиева, Г.М.Әхмәтҗанова . Казан, “Татармультфильм” нәшрияты, 2013 ел.

### Татар теле буенча планлаштырылган нәтиҗәләр

Федераль дәүләт белем бирү стандартлары нигезендә башлангыч сыйныфларда татар теле укытуның нәтиҗәләре билгеләнде.

### Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр

- үзе яшәгән туган җирнең һәм зур ватанның берлеге, бердәмлегенә карата хөрмәт хисләре тууу;
- шәхесара һәм мәдәниара аралашуда татар телен куллануга уңай караштa булу;
- әхлаклылык һәм гуманизм кебек гомумкешелек принципларын, гаилә һәм мәктәп кыймматләрен хөрмәт итү һәм аларны үтәүгә омтылу.

### Метапредмет нәтиҗәләр

- уку максатын (сөйләм бурычын) аңлап, аңа тәңгәл килерлек мәгълүматны сайлый белү;
- гомуми уку күнекмәләренә ия булу һәм үз эшчәнлегеңне оештыра алу;
- үз эшчәнлегеңне планлаштыру, аны контрольдә тоту һәм бәяли белү;
- укылган яки тыңланган мәгълүматның эчтәлегенә бәя бирә белү;
  - өстәмә мәгълүмат алу өчен, белешмә чыганаклардан мөстәкыйль файдалана алу;
  - таблица, схема, кагыйдә формасында бирелгән белешмә материалдан файдалану;

– коммуникациягә керә белү сәләтләре булу;

– парларда, төркемнәрдә эшли белү күнекмәләре булу.

**Сөйләм эшчәнлегенең төрләре буенча татар теленә өйрәтүнең предмет нәтиҗәләре**

Сөйләм эшчәнлегенең төрләре буенча башлангыч мәктәпне тәмамлаучы түбәндәге күнекмәләргә ия була:

**Сөйләү**

– прграмма кысаларында сөйләм бурычына туры килгән лексик-грамматик материалны кулланып, әңгәмәдәшең белән контактка керү: сөйли, сорый белү; сөйләмне башлый, дәвам итә, төгәлли белү;

– телдән монологик сөйләм (тасвирлау, хикәяләү, фикер йөртү) күнекмәләренә ия булу; орфоэпик нормаларны үтәү;

– укыганның эчтәлеген сөйләү, эчтәлеккә карата фикереңне әйтә белү;

– текстны үзгәртеп, аналогик текстлар төзеп сөйләү;

– көндәлек аралашу ситуацияләренә бәйле сөйләм этикеты үрнәкләрен гамәли үзләштерү (сәламләү, саубуллашу, гафу үтенү, рәхмәт әйтү, үтенеч белдерү);

– сөйләм этикеты үрнәкләрен кулланып, гади диалогларда катнашу;

– предметны, персонажны яки рәсемне тасвирлау.

**Тыңлап аңлау**

– аралашу барышында укытучының һәм сыйныфташларның сөйләмен ишетеп аңлау, вербаль яки вербаль булмаган рәвештә җавап кайтару;

– тыңлана торган тексттагы мәгълүматны аңлау, аның эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирү.

**Уку**

– татар сүзенең график образын аның авазлы образы белән чагыштыру;

– укуның орфоэпик һәм интонацион нормаларын белү;

– өйрәнелгән материалга нигезләнгән кечкенә күләмле текстның эчтәлеген аңлап, сәнгатьле итеп һәм әйтелеш нормаларын саклап уку;

– тексттан кирәкле мәгълүматны табу;

– укылган мәгълүматка бәйле гади нәтиҗәләр ясау;

– контекст нигезендә таныш булмаган сүзләрнең мәгънәсенә төшенү.

**Язу**

– тексттан сүзләрне, сүзтезмәләрне, гади җөмләләрне күчереп язу;

– үрнәк буенча бәйрәмгә чакыру язу;

– үрнәк буенча дустыңа хат язу;

– сөйләм бурычын аңлап, кыскача үз фикереңне язмача белдерү.

– текстның эчтәлеге буенча сорауларга язмача җавап бирү;

– терәк сүзләр ярдәмендә кечкенә хикәя төзеп язу;

## II. Укыту предметының эчтәлеге

**Без мәктәпкә барабыз.** Беренче сентябрь. Уку-язу әсбапларының барлыгы, юклыгы, кирәклеге. Уку хезмәте.

**Базарда.** Яшелчәләр. Җиләк-җимешләр. Базарда. Көз билгеләре.

**Мин чисталык яратам.** Шәхси гигиена предметлары. Тән әгъзалары атамалары. Табипта.

**Кыш җитә.** Кыш айлары, кыш билгеләре. Яңа ел бәйрәме. Кышкы уеннар. Кошларга җимлек куябыз.

**Безнең гаилә.** Безнең гаилә. Татар халык ашлары. Өй хезмәте.

**Яз килә.** Яз билгеләре. 8 нче Март – әниләр бәйрәме.

**Минем туган ягым.** Минем туган ягым. Татарстанның табигате. Татарстан шәһәрләре. Мин авылда яшим.

**Кибеттә.** Киемнәр кибетендә. Ашамлыклар кибетендә.

**Җәй.** Җәй билгеләре. Без Сабантуйга барабыз.

**Грамматик минимум**

1. Исемнең төшем килеше белән таныштыру.
2. Исемнәрнең юнәлеш, чыгыш, урын-вакыт килешләрен сөйләмдә куллануны камилләштерү.
3. Исемнәрнең берлек санда 1,2 затта тартым белән төрләнешен сөйләмдә куллануны камилләштерү.
4. Исемнәрнең берлек санда 3 затта тартым белән төрләнеше белән таныштыру (*аның китабы, сумкасы*).
5. Сыйфатның гади дәрәҗәсен сөйләмдә куллану.
6. 11дән 20 кадәр саннарны сөйләмдә куллану.
7. Мин, син зат алмашлыкларын юнәлеш килешендә сөйләмдә куллану.
8. Зат алмашлыкларын күплектә сөйләмдә куллану.
9. Кайчан? сорау алмашлыгы белән таныштыру.
10. Кем? Нәрсә? кайда? кая? кайдан? нинди? ничек? ничә? ничәнче? сорауларына җавап бирә, аларны кулланып, сорау бирә белүне камилләштерү.
10. Хәзерге заман хикәя фигыльнең 1,2,3нче зат юклык формасы белән таныштыру.
11. Билгеле үткән заман хикәя фигыльнең барлыкта һәм юклыкта берлек сан 1,2,3нче зат формасы белән таныштыру.
12. Боерык фигыльнең барлык һәм юклык формалары белән таныштыру.
13. Кирәк, кирәк түгел, ярый, ярамый хәбәрлек сүзләрен сөйләмдә куллану.
14. Чөнки теркәгечен сөйләмдә куллану.

**Орфографик и орфоэпик минимум.**

1. Сузык авазлар. Калын һәм нечкә сузыклар, аларны дөрес әйтү һәм язукүнекмәләрен камилләштерү. Сингармонизм законы. Татар теленең үзенчәлекле сузыклары һәм аларны белдерә торган хәрефләрнең дөрес язылышы. Сүзләрне транскрипция билгеләре белән яза белү.
2. Тартык авазлар. Яңгырау һәм саңгырау авазлар. Алар кергән сүзләрне дөрес әйтә һәм язу күнекмәләрен камилләштерү.
3. Татар алфавитын яттан белү.
4. Сүзләрне иҗекләргә бүлү. Укылган иҗекләр санын билгели белү.
5. Аралашу өчен бирелгән темаларга караган сүзләрнең дөрес әйтелешенә ирешү.
6. Җөмлә ахырында тыныш билгеләрен интонациягә бәйле рәвештә кую.

## III. Төп уку эшчәнлеге төрләре күрсәтелгән тематик планлаштыру

| № | Дәреснең темасы | Дәрес тибы | Үткәрү вакыты | |
|---|---|---|---|---|
| **Тема: Без мәктәпкә барабыз** | | | | |
| 1 | Хәләф Гардановның “Исәнмесез, иптәшләр!” шигырендәге лексик материал | Сәнгатьле итеп сөйләү, уку. | 6.09 | |
| 2 | Минем уку-язу әсбапларым | Лексик берәмлекләрне үзләштерү. | 7.09 | |
| 3 | “Беренче сентябрь” текстындагы лексик-грамматик материал. Кереш конроль эш. | Лексик берәмлекләрне үзләштерү. | 13.09 | |
| 4 | “Бер алма, ике алма ...” санамышы Хаталар өстендә эш. | Лексик берәмлекләрне үзләштерү. | 14.09 | |
| 5 | Мин икенче сыйныфта укыйм | Контроль эш башкару | 20.09 | |
| 6 | “Командир” уены | Хаталар өстендә эш. | 21.09 | |
| 7 | Коля нишли? | Диалог уку, парларда уйнау. | 27.09 | |
| 8 | Мин нишлим? | Уку, тәрҗемә итү. | 28.09 | |
| 9 | “Предметлар кайда?” уены | Диалог төзү. | 4.10 | |
| 10 | Мин Казанда яшим | Тәрҗемә итү, текстны сәнгатьле уку. | 5.10 | |
| 11 | Сумкага нәрсә салам? | Тәрҗемә итү, диалог төзү. | 11.10 | |
| 12 | Мин Казанга барам | Лексик берәмлекләрне үзләштерү. | 12.10 | |
| 13 | Без мәктәпкә барабыз темасы буенча контроль эш. | Контроль эш. | 18.10 | |
| 14 | Сумкадан нәрсә алам? Хаталар өстендә эш. | Диалог төзү. | 19.10 | |
| 15 | Мин Казаннан кайтам | Сәнгатьле итеп уку, тәрҗемә итү. | 25.10 | |
| 16 | “Алсу өйдә булышты” диалогы | Лексик берәмлекләрне үзләштерү. | 8.11 | |
| 17 | Кабатлау-йомгаклау дәресе | Кабатлау | 9.11 | |
| 18 | Көзге уңыш. Яшелчәләр . | Лексик берәмлекләрне үзләштерү. | 15.11 | |
| 19 | Җиләк-җимешләр . | Лексик берәмлекләрне үзләштерү. | 16.11 | |
| 20 | Көзге уңыш. | Лексик берәмлекләрне үзләштерү. | 22.11 | |
| 21 | Базарда” текстындагы лексик-грамматик материал | Лексик берәмлекләрне үзләштерү. | 23.11 | |
| 22 | Базарда | Лексик берәмлекләрне үзләштерү. | 29.11 | |
| 23 | . “Без базарга барабыз” уены. | Тәрҗемә итү. | 30.11 | |
| 24 | Көз билгеләре | Тәрҗемә итү, текстка | 6.12 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | таянып сөйләү. | | |
| 25 | “Алтын көз” текстындагы лексик материал | Сәнгатьле уку. | 7.12 | |
| 26 | Кабатлау-йомгаклау дәресе | Диалог, монолог төзү. | 13.12 | |
| 27 | Контроль эш.<br>Шәхси гигиена предметлары | Мөстәкыйль тәрҗемә итү. | 14.12 | |
| 28 | Хаталар өстендә эш .“Алсу – пөхтә кыз” текстындагы лексик-грамматик материал. Тән әгъзалары атамалары. Комплиментлар әйтү | Тулы җаваплар бирү, сораулар төзү. | 20.12<br>. | |
| 29 | “Марат авырый” текстындагы лексик-грамматик материал. Табипта. | Тулы җаваплар бирү, сораулар төзү. | 21.12 | |
| 30 | Кыш айлары, кыш билгеләре. | Тулы җаваплар бирү, сораулар төзү. | 10.12 | |
| 31 | “Кыш килә” текстындагы лексик материал | Тулы җаваплар бирү, сораулар төзү. | 11.12 | |
| 32 | Яңа ел бәйрәме.<br>“Яңа ел бәйрәме” текстындагы лексик материал.Кабатлау. | Тулы җаваплар бирү, сораулар төзү. | 17.12 | |
| 33 | Кышкы уеннар | Тулы җаваплар бирү, сораулар төзү. | 18.1 | |
| 34 | “Тауда” тексты өстендә эш | Тулы җаваплар бирү, сораулар төзү. | 24.01 | |
| 35 | Тауда” текстындагы лексик-грамматик материал | Тулы җаваплар бирү, сораулар төзү. | 25.01 | |
| 36 | Әйдә бергә уйныйбыз” темасына диалог | Тулы җаваплар бирү, сораулар төзү | 31.01 | |
| 37 | Безнең гаилә. | Мөстәкыйль тәрҗемә итү. | 1.02 | |
| 38 | “Безнең гаилә” текстындагы лексик материал | Тексттан сорауларга җавап табу. | 7.02 | |
| 39 | Ш. Маннурның “Яратам”шигыре | Тәрҗемә белән сәнгатьле уку. | 8.02 | |
| 40 | Мин әнине яратам. | Сөйләмдә тылсымлы сүзләр куллану. | 14.02 | |
| 41 | Татар халык ашлары. | Тексттан сорауларга җавап табу. | 15.02 | |
| 42 | Татар халык ашлары. | Тексттан сорауларга җавап табу. | 21.02 | |
| 43 | Без өстәл әзерлибез | Тексттан сорауларга җавап табу. | 22.02 | |
| 44 | “Безнең гаилә” темасын кабатлау | Тулы җаваплар бирү, сораулар төзү. | 28.02 | |
| 45 | . Яз билгеләре. Фатих Кәримнең “Яз җитә” шигырендәге лексик материал | Көйгә салып җырлау. | 1.03 | |
| 46 | 8 нче Март - әниләр бәйрәме. | Текстны аңлап уку. | 7.03 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 47 | Әниләр бәйрәменә котлау язу “Яз” темасын кабатлау | Тулы җаваплар бирү, сораулар төзү. | 8.03 | |
| 48 | .Мин Татарстанда яшим. Контроль эш | Сорау алмашлыкларын гамәли куллану. | 14.03 | |
| 49 | Хаталар өстендә эш. | “Минем туган ягым “темасына хикәя төзү. | 15.03 | |
| 50 | Мин Татарстанда яшим темасы буенча | Үзеңнең шәһәрең турында җөмләләр төзү. | 21.03 | |
| 51 | Туган ягым текстындагы лексик материал | Сорауларга җавап бирү. Нинди транспортта барганыңны әйтә белү. Кайсы шәһәргә барганны сорый белү | 22.03 | |
| 52 | Татарстанның табигате. | Хикәягә исем бирү. | 4.04 | |
| 53 | Без шәһәрдә яшибез | Лексик танышу | 5.04 | |
| 54 | “Мин авылда яшим” текстындагы лексик-грамматик материал | Тулы җаваплар бирү, сораулар төзү. | 11.04 | |
| 55 | “Мин авылда яшим” текстындагы лексик-грамматик материал | Сорауларга җавап бирү. | 12.04 | |
| 56 | Кибеттә.Киемнәр кибете | Диалогларны рольләргә бүлеп уку. | 18.04 | |
| 57 | “Матур киемнәр” текстындагы лексик-грамматик материал. | Текст буенча сораулар бирү. | 19.04 | |
| 58 | Кибеттә сату-алу | Тулы җаваплар бирү, сораулар төзү. | 25.04 | |
| 59 | Кибеттә. Ашамлыклар кибете | Кушымчаларны дөрес куллану. | 26.04 | |
| 60 | Ашамлыклар кибетендә<br><br>сатып-алу | Тулы җаваплар бирү, сораулар төзү. | 2.05 | |
| 61 | Кабатлау-йомгаклау дәресләре | Тулы җаваплар бирү, сораулар төзү | 3.05 | |
| 62 | “Исәнме, җәй!” рәсеме буенча сөйләш | Текст буенча сораулар бирү. | 9..05 | |
| 63 | “Җәй җитте” текстындагы лексик материал | Сәнгатьле уку. | 10.05 | |
| 64 | Сабантуй – күңелле бәйрәм. | Сәнгатьле уку. “Сабантуйда” рәсеме буенча кем нишли? соравына җавап бирү | 16.05 | |
| 65 | Йомгаклау контроль эше | Диалогларны рольләргә бүлеп уку. “Сабантуйда” рәсеме буенча кем нишли? соравына җавап | 17.05 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | бирү | | |
| 66 | Аралаша белү күнекмәләрен ситуатив күнегүләр аша тикшерү | Тулы җаваплар бирү, сораулар төзү. | 23.05 | |
| 67 | Сабантуй – күңелле бәйрәм. | Контроль эш | 24.05 | |
| 68 | Хаталар өстендә эш. | Хаталарны төзәтү. | 27.05 | |
| 69 | Ел буенча үткәннәрне кабатлау | Кагыйдәләрне искә төшерү,практикада куллану | 30.05 | |
| 70 | Ел буенча үткәннәрне кабатлау | Кагыйдәләрне искә төшерү,практикада куллану | 31.05 | |